# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм "Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Актаныш муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп корырга:

1) "Чишмә авыл җирлеге"н һәм "Аккүз авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Аккүз авылы булган "Аккүз авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән;

2) "Яңа Кормаш авыл җирлеге"н һәм "Татар Суыксуы авыл җирлеге"н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Татар Суыксуы авылы булган "Татар Суыксуы авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән "Аккүз авыл җирлеге", "Татар Суыксуы авыл җирлеге" (алга таба – яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр) муниципаль берәмлекләренең беренче чакырылыш вәкиллекле органнары депутатларының һәм беренче башлыкларының вәкаләтләре чорын биш ел дип билгеләргә.

2. Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органнарындагы депутатлар санын ун кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумнарда кабул ителүче яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлек башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

"Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 11 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аккүз авыл җирлеге: Аккүз (административ үзәк), Чишмә, Ахун, Яңа Кадермәт, Меңнәр авыллары, Михайловка поселогы;";

б) унөченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


"Татар Суыксуы авыл җирлеге: Татар Суыксуы (административ үзәк), Мари Суыксуы, Яңа Кормаш, Карт авыллары, Югары Карач, Түбән Карач поселоклары;";

г) егерме сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Актаныш муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

# “Актаныш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләрен тасвирлау

1 (19) - 55 (20) - Удмурт Республикасы һәм Башкортостан Республикасы
55 (20) - 49 (70) - Мөслим муниципаль районы
49 (70) - 1 (19) - Минзәлә муниципаль районы

"Актаныш муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Аеш авыл җирлеге |
| 2 | Аккүз авыл җирлеге |
| 3 | Актанышбаш авыл җирлеге |
| 4 | Актаныш авыл җирлеге |
| 5 | Әтәс авыл җирлеге |
| 6 | Югары Яхшый авыл җирлеге |
| 7 | Кәзкәй авыл җирлеге |
| 8 | Киров авыл җирлеге |
| 9 | Күҗәкә авыл җирлеге |
| 10 | Мәсәде авыл җирлеге |
| 11 | Яңа Әлем авыл җирлеге |
| 12 | Пучы авыл җирлеге |
| 13 | Иске Айман авыл җирлеге |
| 14 | Иске Байсар авыл җирлеге |
| 15 | Иске Богады авыл җирлеге |
| 16 | Иске Кормаш авыл җирлеге |
| 17 | Иске Сәфәр авыл җирлеге |
| 18 | Такталачык авыл җирлеге |
| 19 | Татар Суыксуы авыл җирлеге |
| 20 | Татар Ямалысы авыл җирлеге |
| 21 | Теләкәй авыл җирлеге |
| 22 | Түке авыл җирлеге |
| 23 | Уразай авыл җирлеге |
| 24 | Усы авыл җирлеге |
| 25 | Чалманарат авыл җирлеге |
| 26 | Чуракай авыл җирлеге |

";

3) 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Актаныш муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Актаныш муниципаль районының**
**"Аккүз авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Аккүз авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Аккүз авыл җирлеге Яңа Әлем, Иске Байсар, Иске Богады, Иске Сәфәр авыл җирлекләре һәм Башкортостан Республикасы белән чиктәш.

**Актаныш муниципаль районының**
**"Аккүз авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Аккүз авыл җирлеге чиге Иске Байсар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аккүз, Иске Байсар авыл җирлекләре һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 29 нчы урман кварталының көньяк почмагында урнашкан 52 нче тоташу ноктасыннан алып 2,5 км төньяк-көнбатышка таба "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 29, 26, 25 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 3,4 км төньяк-көнчыгыш юнәлештә "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 25, 179, 177, 175 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 380 м көнбатышка таба, Сөн елгасын, күлне, Актаныш – Мөслим автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,4 км төньяк-көнбатышка таба уза, алга таба 1,9 км урман полосасының төньяк-көнчыгыш ягыннан Аккүз, Иске Байсар һәм Иске Сәфәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Аккүз авылыннан 4,0 км көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Аккүз авыл җирлеге чиге Иске Сәфәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягыннан, 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Терпеле инешенә кадәр уза, алга таба 2,6 км төньяк-көнбатышка

таба бу инеш буенча аска таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 430 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 140 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 620 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км төньяк-көнбатышка таба, "Актаныш – Мөслим" – Киров исемендәге совхоз" автомобиль юлын кисеп үтеп, 70 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары шул ук юнәлештә 990 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягыннан Аккүз, Иске Богады һәм Иске Сәфәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Терпеле поселогыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Аккүз авыл җирлеге чиге Иске Богады авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аккүз, Яңа Әлем һәм Иске Богады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чишмә авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньяк-көнчыгышка таба, 2,0 км көньяк-көнбатышка, 640 м көньяк-көнчыгышка, 3,0 км көньяк-көнбатышка, "Актаныш – Мөслим" – Чишмә – Меңнәр автомобиль юлын юллар чатыннан 300 м көнчыгыштарак кисеп үтеп, 2,1 км көньяк-көнбатыш юнәлештә, 100 м көньякка таба, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Актаныш–Мөслим автомобиль юлы буйлап уза, алга таба, "Актаныш – Мөслим" – Киров исемендәге совхоз" автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,8 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары шул ук юнәлештә 1,0 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Аккүз авыл җирлеге чиге Яңа Әлем авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап, 350 м көнчыгышка таба урман массивы буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 130 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 120 м куаклык буйлап, 70 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 40 м куаклык буйлап "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 166 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, алга таба бу урманчылык чиге буйлап 290 м төньяк-көнчыгышка таба, 250 м көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба, аннары 240 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба урман массивы буйлап 170 м төньяк-көнчыгышка таба, 310 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары шул ук юнәлештә 230 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 380 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба көньякка таба 110 м урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 120 м сазлык буйлап, 520 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 30 м Сөн елгасы буйлап Яңа Әлем, Чишмә авыл җирлекләре һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында Чишмә авылыннан 3,8 км көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Аккүз авыл җирлеге чиге Башкортостан Республикасы белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 52 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

4) 7 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Яңа Кормаш," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әтәс авыл җирлеге чиге Татар Суыксуы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Әтәс, Күҗәкә һәм Татар Суыксуы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Үрьяды авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 110 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 790 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба 950 м урман полосасының көнбатыш ягыннан, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әтәс, Иске Кормаш һәм Татар Суыксуы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Кормаш авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 13 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңа Әлем авыл җирлеге Аеш, Аккүз, Актанышбаш, Актаныш, Иске Богады, Теләкәй, Уразай авыл җирлекләре һәм Башкортостан Республикасы белән чиктәш.";

б) тугызынчы абзацта "Яңа Әлем, Иске Богады һәм Чишмә" сүзләрен "Аккүз, Яңа Әлем һәм Иске Богады" сүзләренә алмаштырырга;

в) унынчы абзацта "Чишмә" сүзен "Аккүз" сүзенә, "Яңа Әлем, Чишмә" сүзләрен "Аккүз, Яңа Әлем" сүзләренә алмаштырырга;

6) 14 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 18 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Иске Сәфәр, Теләкәй һәм Чишмә" сүзләрен "Иске Сәфәр һәм Теләкәй" сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта "Яңа Әлем, Иске Богады һәм Чишмә" сүзләрен "Аккүз, Яңа Әлем һәм Иске Богады" сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Иске Богады авыл җирлеге чиге Аккүз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньяк-көнчыгышка таба, 2,0 км көньяк-көнбатышка, 640 м көньяк-көнчыгышка, 3,0 км көньяк-көнбатышка, "Актаныш – Мөслим" – Чишмә – Меңнәр автомобиль юлын юллар чатыннан 300 м көнчыгыштарак кисеп үтеп, 2,1 км көньяк-көнбатыш юнәлештә, 100 м көньякка таба, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Актаныш – Мөслим автомобиль юлы буйлап уза, алга таба, "Актаныш – Мөслим" – Киров исемендәге совхоз" автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,8 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары шул ук юнәлештә 1,0 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап Аккүз, Иске

Богады, Иске Сәфәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Терпеле поселогыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

8) 19 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Яңа Кормаш," сүзләрен төшереп калдырырга, "Такталачык" сүзеннән соң ", Татар Суыксуы" сүзләрен өстәргә;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Иске Кормаш авыл җирлеге чиге Татар Суыксуы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Кормаш, Такталачык һәм Татар Суыксуы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Балтач авылыннан 3,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып 30 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, "Актаныш – Пучы" – Татар Суыксуы автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба Әтәс, Иске Кормаш һәм Татар Суыксуы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Кормаш авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

9) 20 нче кушымтада текстның татарчасы үзгәрми;

10) 21 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Яңа Кормаш," сүзләрен төшереп калдырырга, "Иске Кормаш," сүзләреннән соң "Татар Суыксуы," сүзләрен өстәргә;

б) алтынчы абзацта "Яңа Кормаш," сүзләрен төшереп калдырырга, "Такталачык" сүзеннән соң ", Татар Суыксуы" сүзләрен өстәргә;

в) җиденче абзацта "Яңа Кормаш" сүзләрен "Татар Суыксуы" сүзләренә, "Яңа Кормаш, Иске Кормаш һәм Такталачык" сүзләрен "Иске Кормаш, Такталачык һәм Татар Суыксуы" сүзләренә алмаштырырга;

11) 22 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Актаныш муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

**Актаныш муниципаль районының**
**"Татар Суыксуы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Татар Суыксуы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Актаныш муниципаль районы"

муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Татар Суыксуы авыл җирлеге Әтәс, Күҗәкә, Иске Кормаш, Такталачык, Татар Ямалысы, Чалманарат авыл җирлекләре, Минзәлә муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

**Актаныш муниципаль районының "Татар Суыксуы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Татар Суыксуы авыл җирлеге, Минзәлә муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Татар Суыксуы авылыннан 18,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан X=483776,51, Y=3198366,70 координаталы 1 нче (19 нчы) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Татар Суыксуы, Татар Ямалысы авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Бүләк авылыннан 15,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан X=488490,52, Y=3205566,92 координаталы 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Татар Ямалысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып 15,6 км көньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычының су басу зонасы буйлап уза, алга таба Карт – Бүләк, "Актаныш – Пучы" – Бүләк автомобиль юлларын һәм урман полосасын кисеп үтеп, 1,9 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Татар Суыксуы, Татар Ямалысы һәм Чалманарат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бүләк авылыннан 1,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Чалманарат авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба шул ук юнәлештә 1,31 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шабиз елгасына кадәр уза, алга таба 2,3 км Шабиз елгасы агымы буенча аска таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягыннан "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 98 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, алга таба әлеге урманчылыктагы 98 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш ягыннан уза, аннары урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап әлеге урманчылыктагы 182 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба 182 нче урман кварталының көнчыгыш, төньяк, көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап 3,0 км уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Такталачык, Татар Суыксуы һәм Чалманарат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Карач поселогыннан 3,0 км көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Такталачык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып 860 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 107 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр уза, алга таба 2,7 км көньяк юнәлештә бу урманчылыктагы 107, 108 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап Иске Кормаш, Такталачык һәм Татар Суыксуы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Балтач авылыннан 3,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Иске Кормаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып 30 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман массивының төньяк-көнбатыш чигеннән бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, "Актаныш – Пучы" – Татар Суыксуы автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба Әтәс, Иске Кормаш һәм Татар Суыксуы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Кормаш авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Әтәс авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Әтәс, Күҗәкә һәм Татар Суыксуы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Үрьяды авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 850 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 110 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 790 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 350 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м урман полосасының көнбатыш ягыннан, көньяк-көнчыгышка таба 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Күҗәкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Пучы – Мари Суыксуы автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 850 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, 650 м төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 480 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 52 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба 330 м көньяк-көнбатышка таба 52 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары Түбән Кама сусаклагычының яр буе линиясе буйлап 820 м көньяк-көнбатыш юнәлештә, 400 м төньяк юнәлештә бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба 210 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 480 м урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан уза, аннары Түбән Кама сусаклагычының су басу зонасы буйлап 160 м көньяк-көнбатышка таба, 80 м төньяк-көнбатышка таба, 110 м көньяк-көнбатышка таба, 3,9 км төньяк-

көнбатышка таба Күҗәкә, Татар Суыксуы авыл җирлекләре һәм Минзәлә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Адай авылыннан 4,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Суыксуы авыл җирлеге чиге Минзәлә муниципаль районы белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Актаныш муниципаль районы чиге буйлап 1 нче (19 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.";

12) 28 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Яңа Кормаш," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чалманарат авыл җирлеге чиге Татар Суыксуы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба шул ук юнәлештә 1,31 км урман полосасының көньяк-көнбатыш ягыннан, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Шабиз елгасына кадәр уза, алга таба 2,3 км Шабиз елгасы агымы буенча аска таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш ягыннан "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 98 нче урман кварталының көнбатыш почмагына кадәр уза, алга таба әлеге урманчылыктагы 98 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш ягыннан уза, аннары урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 320 м көньяк-көнбатышка таба әлеге урманчылыктагы 182 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба 182 нче урман кварталының көнчыгыш, төньяк, көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап 3,0 км уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Такталачык, Татар Суыксуы һәм Чалманарат авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Карач поселогыннан 3,0 км көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

13) 29 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 87-ТРЗ